**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сапеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

ул. Школьная, д.53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сэпэй авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Школьная урамы , 53В, Сэпэй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40
Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» ноябрь 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак
пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1.Сәпәй авылы Совет урамы 1 йорттан 16 йортка кадәр, Тукай урамы 1 йорттан 33 йортка кадәр, Х.Шарапова урамы урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр, Г.Хәсәншина урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр, Һ.Такташ урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр, Казан урамы 1 йорттан 18 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2024 елның 15 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Сәпәй авылы Мәктәп урамы 1 йорттан 55 йортка кадәр, 1 Май урамы 1 йорттан 22 йортка кадәр, Чапаев урамы 1 йорттан 32 йортка кадәр, А.Алиш урамы 1 йорттан 11 йортка кадәр, Нефтьчеләр урамы 1 йорттан 15 йортка кадәр, Яңа урам 1 йорттан 50 йортка кадәр, Совет урамы 18 йорттан 20 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2024 елның 15 ноябрендә 12.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, гаиләләрендә гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында

контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә юнәлдерелгән, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түяү, алып китү, тигезләү);

- Сәпәй торак пункты территориясын төзекләндерү:

а) чүп үләне чаптыру;

б) чүп җыю;

в)кар җыештыру (тракторчының хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Ф.Г.Галиева